| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.10.2018 Казан ш. № 7-9/т

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә шәһәр яны юнәлешендәге даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында

«Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законнарга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан көйләүне тәртипкә китерү буенча чаралар турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 нчы Карарына, ««Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 нче Карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, һәм шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 19 апрелендәге 261 нче карары белән расланган 2018-2020 елларда Татарстан Республикасы территориясе буенча узучы шәһәр яны маршрутларында көйләнелә торган тарифлар буенча даими йөртүләрне (ташуларны) оештыру буенча чаралар планының («юл картасының») 2 пунктын үтәү максатларында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә шәһәр яны юнәлешендәге даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында

даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын әлеге карарга теркәлгән кушымтага ярашлы билгеләргә.

2. Түбәндәге карарларның үз көчен югалтуын танырга:

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча комитеты Идарәсенең «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында шәһәр яны юнәлешендә автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташуга  тарифлар билгеләү турында» 2010 елның 16 апрелендәге 7-10/т номерлы карары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитет Идарәсенең «Минзәлә АТП» ҖЧҖ тарафыннанТатарстан Республикасы Минзәлә районында шәһәр яны юнәлешендә автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында» 2010 елның 30 июнендәге 7-2/т номерлы карары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты Идарәсенең «Транспорт» ҖЧҖ тарафыннанТатарстан Республикасы Ютазы районында шәһәр яны юнәлешендә автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында» 2010 елның 30 июнендәге 7-3/т номерлы карары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты Идарәсенең «Аксубай АТП» ААҖ һәм «Транспорт» ҖЧҖ  тарафыннанТатарстан Республикасы Аксубай районында шәһәр яны юнәлешендә автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә иң чик максималь тарифларны билгеләү турында» 2010 елның 16 июлендәге 7-11/т номерлы карары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты Идарәсенең «Баулы АТП» ААҖ, «Вахтовик» ҖЧҖ  һәм «Флигентов Р.М.» ШЭ тарафыннанТатарстан Республикасы Баулы муниципаль районында шәһәр яны юнәлешендә автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында» 2010 елның 27 августындагы 7-17/т номерлы карары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының  «ПАК-Инвест» ЯАҖ,  Тимергалин Р.Р. ШЭ,  Габдрахманов Р.М. ШЭ, Айдаров Э.М. ШЭ, Шәймәхәмммәтов Р.А. Ш., Потапов А.С. ШЭ, Төхбәтуллин Р.Г. ШЭ, ИП Вәлиуллин Н.Х. ШЭ  тарафыннан Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында шәһәр яны юнәлешендә гомуми кулланыштагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында» 2011 елның 18 мартындагы 7-11/т номерлы карары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Казан ПАТП-1» ААҖ тарафыннан Татарстан Республикасы Югары Ослан, Биектау, Лаеш һәм Питрәч муниципаль районнарында шәһәр яны юнәлешендә автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында» 2011 елның 15 июлендәге 7-29/т номерлы карары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Азнакай ПАТП» ААҖ, «Азнакай транспорты-1» ҖЧҖ  һәм «Азнакай транспорты-2» ҖЧҖ тарафыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында шәһәр яны юнәлешендә гомуми кулланыштагы  автомобиль транспортында пассажирлар йөртү

һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында» 2011 елның 28 октябрендәге 7-37/т номерлы карары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Балык Бистәсе ПАТП» ҖЧҖ тарафыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында шәһәр яны юнәлешендә гомуми кулланыштагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында» 2012 елның 24 августындагы 7-23/т номерлы карары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Арча АТП» ААҖ, «Фил» ҖЧҖ, «Автомобилист» ҖЧҖ тарафыннан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында шәһәр яны юнәлешендә гомуми кулланыштагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында» 2012 елның 31 августындагы 7-25/т номерлы карары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында шәһәр яны юнәлешендә гомуми кулланыштагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында» 2012 елның 26 октябрендәге 7-28/т номерлы карары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Казан ПАТП-1» ААҖ тарафыннан Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында шәһәр яны юнәлешендә гомуми кулланыштагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында» 2014 елның 6 июнендәге 7-10/т номерлы карары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Экспресс» ҖЧҖ һәм «Седьмое ЧАТО» ҖЧҖ тарафыннан Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районында шәһәр яны юнәлешендә гомуми кулланыштагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында» 2014 елның 6 июнендәге 7-11/т номерлы карары;

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 5 октябрендәге 7-9/т номерлы
боерыгына кушымта

## Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә шәһәр яны юнәлешендәге даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифлары

| т/б № | Муниципаль берәмлек | Бер пассажирны йөртүгә иң чик максималь тариф, юлның бер километрына сум/ пасс.-км | Бер урынлык багаж ташуга иң чик максималь тариф, юлның бер километрына сум/км да |
|---|---|---|---|
| 1. | Азнакай муниципаль районы | 2,0 | 0,30 |
| 2. | Аксубай муниципаль районы | | |
| 3. | Апас муниципаль районы | | |
| 4. | Баулы муниципаль районы | | |
| 5. | Балтач муниципаль районы | | |
| 6. | Буа муниципаль районы | | |
| 7. | Югары Ослан муниципаль районы | | |
| 8. | Биектау муниципаль районы | | |
| 9. | Чүпрәле муниципаль районы | | |
| 10. | Яшел Үзән муниципаль районы | | |
| 11. | Кайбыч муниципаль районы | | |
| 12. | Кама Тамагы муниципаль районы | | |
| 13. | Кукмара муниципаль районы | | |
| 14. | Лаеш муниципаль районы | | |
| 15. | Менделеевск муниципаль районы | | |
| 16. | Минзәлә муниципаль районы | | |
| 17. | Яңа Чишмә муниципаль районы | | |
| 18. | Питрәч муниципаль районы | | |
| 19. | Балык Бистәсе муниципаль районы | | |
| 20. | Сарман муниципаль районы | | |
| 21. | Спас муниципаль районы | | |
| 22. | Тәтеш муниципаль районы | | |
| 23. | Тукай муниципаль районы | | |
| 24. | Чирмешән муниципаль районы | | |
| 25. | Ютазы муниципаль районы | | |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге